ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 декабря 2022 г. № 7484

Муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3943 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1.2 пункт өстәргә:

«1.1.2. Регламент нигезләмәләре, җир участокларыннан, муниципаль торак фондының торак урыннарыннан, дини билгеләнештәге муниципаль мөлкәттән тыш, муниципаль казнаны тәшкил итүче мөлкәткә кагыла.»;

2) 2.3.1 пунктның 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

3) 2.5.1. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Граждан кодексы 30.11.1994, № 51-ФЗ (РФ законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, ст. 3301) (алга таба – РФ Граждан кодексы);

2) «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 31.07.2006, № 31 (1 өлеш), ст. 3434) (алга таба – 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон);

3) «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 03.08.1998, № 31 ст. 3813) (алга таба – 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон);

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

5) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

6) «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 190-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4159);

7) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.04.2011, № 15, ст. 2036);

8) «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 416-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.12.2011, № 50, ст. 7358);

9) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы (Республика Татарстан, 03.08.2004, № 155-156) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

10) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (Челнинские известия, №№ 235-237, 10.12.2005, № 249-250, 30.12.2005) (алга таба – Устав);

11) Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмә (Челнинские известия, № 203-204, 04.10.2007) (алга таба – 25/5 номерлы Нигезләмә);

12) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 18 сентябрендәге 2113-2 номерлы карары белән расланган Типлаштырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Типлаштырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге);

13) Башкарма комитетның 2021 елның 8 апрелендәге 246-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

14) Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – ҖММИ турында нигезләмә);

15) Башкарма комитетның 2011 елның 12 апрелендәге 1816 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтен арендага бирү процедурасы турында нигезләмә («Челнинские известия» 15.04.2011, №54)

16) Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).»;

4) 2.7.1 пунктта:

- 2 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар, Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар яисә һөнәри керемгә салым түләүченең статусы (үзмәшгуль) турында мәгълүматлар – Федераль салым хезмәте;»;

- түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча өстәргә:

«8) белем бирү яки медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия – лицензияләүче орган.»;

5) 2.8.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар (Регламентка 3 нче кушымта) гариза бирүчене кабул итү вакытында, шулай ук ҖММИ белгече тарафыннан гариза бирүчедән гариза һәм документлар кабул ителгәннән соң, гаризаны теркәгән көннән башлап тугыз эш көненнән артмаган срокта кабул ителергә мөмкин;»;

6) 2.9.2 пунктта:

- 3 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү датасына сорала торган муниципаль мөлкәткә карата, Башкарма комитетның хокукый акты нигезендә аны башка затка бирү турында карар кабул ителгән;»;

- түбәндәге эчтәлектәге 12-14 пунктчалар өстәргә:

«12) сорала торган муниципаль мөлкәт өченче затларның хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, шәхси эшмәкәр булмаган һәм Башкарма комитетның норматив хокукый акты нигезендә «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларның мөлкәти хокукларыннан тыш);

13) гариза бирүченең мөрәҗәгатен теркәү датасына гариза бирүченең төзелгән аренда, муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәләре буенча бурычы (шул исәптән пеня һәм штрафлар буенча бурычлары) булу;

14) 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 пунктының 6 пунктчасы нигезендә, муниципаль хезмәттән файдалануга дәгъва кылучы гариза бирүченең гамәлдәге лицензияләре турында мәгълүматлар лицензияләр реестрында булмау.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов